**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 1 и 3 Закона Республики Татарстан «О приватизации государственного имущества Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
5 июня 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 26 июля 2004 года № 43-ЗРТ «О приватизации государственного имущества Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (I часть); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I часть); 2016, № 10) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 1 после слов «Федерального закона» дополнить словами «от 21 декабря 2001 года № 178-ФЗ»;

2) в части 3 статьи 3:

а) пункт 5 дополнить словами «, а также своим решением поручает юридическим лицам, указанным в подпункте $8^1$ пункта 1 статьи 6 Федерального закона от 21 декабря 2001 года № 178-ФЗ «О приватизации государственного и муниципального имущества», организовывать от имени Республики Татарстан в установленном порядке продажу приватизируемого государственного имущества и (или) осуществлять функции продавца такого имущества»;

б) в абзаце тринадцатом слово «Уполномоченный» заменить словами «4. Уполномоченный»;

в) абзац четырнадцатый признать утратившим силу.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
21 июня 2019 года
№ 47-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «Федераль закон» сүзләре алдыннан «2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) 5 пунктта «, шулай ук «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының $8^1$ пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга үзенең карары белән Татарстан Республикасы исеменнән хосусыйлаштырыла торган дәүләт мөлкәтен билгеләнгән тәртиптә сатуны оештырырга һәм (яисә) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашырырга йөкләмә бирә» сүзләрен өстәргә;

б) унөченче абзацта «Башкарма» сүзен «4. Башкарма» сүзләренә алмаштырырга;

в) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 21 июнь
№ 47-ТРЗ